# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

## КАРАР № 21

III чакырылыш    XXVII утырыш   Урыссу штб         «26» август  2019 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым
йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итү
өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына
башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибен
раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 28 мартындагы «Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 233 санлы карары нигезендә, һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында, Ютазы муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирүнең кушымтадагы Тәртибен расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

*Ютазы муниципаль районы Башлыгы –*
*Ютазы район Советы рәисе*                                   *Р.М. Нуриев*

Кушымта №1
Ютазы район Советының 2019 елның 26 августындагы. № 21 Карарына

## Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар, муниципаль берәмлекләр) бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Ютазы муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасында һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар, алар Татарстан Республикасы бюджетыннан кергән көннән соң, 3 эш көне эчендә шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына квартал саен бирелә.

4. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын төп бүлүче булып Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Финанс – бюджет палатасы (алга таба - Финанс-бюджет палатасы) тора.

5. Башка бюджетара трансфертларны бүлү һәм аларның күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

6. Муниципаль район составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү шарты - җирлекнең башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнарның юнәлешләрен билгеләүче аерым тәртиптә кабул ителгән норматив хокукый актының булуы .

7. Җирлекләрнең башкарма комитетлары Финанс-бюджет палатасына Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча һәм тәртиптә башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыралар.

8. Әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмаган очракта, агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Финанс-бюджет палатасының финанс хисап елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә, күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларның калдыгыннан артмаган

күләмдә акчалар агымдагы финанс елында шәһәр һәм авыл җирлеге бюджеты keремәнә кире кайтарылырга мөмкин.

Әгәр әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертларның кулланылмаган калдыгы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты керемнә күчерелмәгән очракта, әлеге акчалар, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты керемнә кайтарылырга (подлежит взысканию) тиеш.

9. Җирлекләр башкарма комитетлары һәм вазыйфаи затлар, закон нигезендә, тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәү өчен җаваплы.

10. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты керемнә күчерелергә тиеш.

11. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны Финанс-бюджет палатасы башкара.